**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Исполнительный комитет Чалпинского
сельского поселения
Азнакаевского
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге
башкарма комитеты

ул. Центральная, д..35, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5--46, факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» август 2018 ел. № 12

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февралендәге 92 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (09.09.2016 №38, 28.11.2016 №46, 04.09.2017 №68 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февралендәге 92 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (09.09.2016 №38, 28.11.2016 №46, 04.09.2017 №68 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 36 статьяга. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары:

- Индивидуаль торак йортлар белән торак төзелешенең территориаль зонасы өчен шәһәр төзелеше регламентларына күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата җир кишәрлекләренең максималь чик күләмнәрен билгеләү өлешендә үзгәреш кертергә - 5000 кв.м».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм срокларын (1 нче кушымта) билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: ____________________________ А.М.Мөхәммәтшин

Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Башкарма комтетының 2018 елның 07 августындагы 12 номерлы карарына №1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Чалпы авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен уздыру тәртибе һәм вакыты**

| N | «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен якынча уздыру вакыты | Эшләр уздыру вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча эшләр оештыру. | 2018 елның III кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләр әзерләү. | 2018 елның III кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект турында фикер алышу.<br>Гавами тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районы башлыгына «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешләренең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект юлламасы<br>Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешен раслауга яисә аны кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, аны эшләп бетерергә җибәрү турында карар кабул итү өчен кушымталар (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) җибәрү. | 2018 елның III- IV кварталы |